МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

09.03.2023 Казан шәһәре 56

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында вазыйфа биләү коррупция хәтәрләренә бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2021 елның 10 ноябрендәге 442 номерлы боерыгына үзгәреш кертү хакында

Норматив хокукый актны «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) администрациясе турында» 2023 елның 4 февралендәге ПУ-68 номерлы Указына туры китерү максатларында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында вазыйфа биләү коррупция хәтәрләренә бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан

хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2021 елның 10 ноябрендәге 442 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2022 елның 10 ноябрендәге 380 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) үзгәреш кертеп, 2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына һәм Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенә әлеге Боерыкның 1 пункты нигезендә расланган вазыйфалар исемлеген расланган көннән өч көн эчендә тапшырырга, ә аннан соң, аңа үзгәрешләр керткәндә, үзгәрешләр кертелгәннән соң бер атна эчендә вазыйфаларның төгәлләнгән исемлеген тапшырырга.».

**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры урынбасары –**
**министр** **М.Р.Шаһиәхмәтов**